**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ҖӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

«15 ноябрь 2024 ел №170

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы берәмлегенә тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Олы Җәке авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Олы Җәке авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2024 елның 26 мартындагы 144 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru шулай ук Олы Яке

авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1а (КФҮ) адреслары буенча Олы Яке авылы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Олы Яке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: Ф. А. Фәйзуллина